КАРАР

№ 19 25.02.2021 г.

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда халык җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында Күңгәр авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 107 карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатыннан, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Күңгәр авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел, № 107 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» гы нигезлэмэгэ үзгәрешләр кертү:

**1.1. Нигезләмәнең 1.7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 11 абзац өстәргә:**

- инициативалы проектларны тәкъдим итү , әзерләү , сайлап алу һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль берәмлекнең
вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә»;

1.2. 3. 20 пунктны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

« Әгәр гражданин җитди сәбәпләр ( сәламәтлек ,инвалидлык һ. б.) буенча гражданнар җыенын да катнаша алмаса, гражданинның фамилиясе , исеме һәм атасының исеме , аның яшәү урыны , аның гражданнар җыенында катнаша алмавы сәбәбе , шулай ук аның гражданнар җыенына чыгарыла торган үзарасалым акчаларын кертү һәм кулану мәсьәләсенә турыдан-туры мөнәсәбәте аның гаризасы нигезендә гражданнар җыенында исәпкә алына».

2.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Күңгәр авыл җирлеге Башлыгы: И.И.Салахов